| | | |
|---|---|---|
| АЛЕКСЕЕВСКИЙ<br>РАЙОННЫЙ СОВЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>РАЙОН СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.08.2021 п.г.т. Алексеевское № 56

**Авыл хуҗалыгы җирләрен хосусыйлаштыру вакытына билгеләнгән гражданнар милкенә җир кишәрлекләрен бушлай тапшыруның уртача район нормасын билгеләү турында**

Татарстан Республикасы Җир кодексының 34 маддәсендәге 1 пункты һәм авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән төзелә торган яңа җир кишәрлегенең минималь күләмен билгеләү максатларында, крестьян (фермер) хуҗалыгы белән аның эшчәнлеген дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдән гамәлгә ашыру өчен милек итеп бирелә торган җир кишәрлекләренең иң чик минималь күләмен билгеләү максатларында, Татарстан Республикасы Җир кодексының 40 маддәсендәге 2 пункты нигезендә авыл хуҗалыгы җирләрен Алексеевск районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре чикләрендә гражданнарның милкенә түләүсез тапшыру йомгаклары нигезендә, «Җир кишәрлекләрен гражданнар милкенә түләүсез тапшыру нормасын билгеләү тәртибе турында» 1992 елның 02 мартындагы 213 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы һәм РСФСР Дәүләт комитетының җир реформасы һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына ярдәм итү буенча 1992 елның 10 гыйнварындагы 3-15/51 номерлы хаты нигезендә

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә авыл хуҗалыгы җирләрен хосусыйлаштыру вакытына гражданнарның милкенә 8,3 гектар күләмендә җир кишәрлекләрен бушлай тапшыруның уртача район нормасын билгеләргә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының Рәсми порталында Алексеевск муниципаль районының Рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск муниципаль районы Советының экология, җир мәсьәләләре, төзелеш, ТКХ һәм транспорт буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

**Алексеевск муниципаль**
**районы башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.А. Демидов**